ГЛАВА
НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422670, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, ул Советская., дом 72А,
с.Верхний Тимерлек

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

422670,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Совет урамы, 72А йорты,
Югары Тегермәнлек авылы

Тел.: (8-4361) 28001 , факс: (8-4361) 28001 , эл.адрес: Ntim.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 16 ноябре Югары Тегермәнлек авылы № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә, җыенны уздыру урыны Түбән Тегермәнлек авыл клубы.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 30 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә, җыенны уздыру урыны Түбән Тегермәнлек авыл клубы.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә, җыенны уздыру урыны Югары Тегермәнлек авыл мәдәният йорты.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 30 ноябрендә

13 сәг. 00 минутка билгеләргә, җыенны уздыру урыны Югары Тегермәнлек авыл мәдәният йорты.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 30 ноябрендә 15 сәг. 00 минутка билгеләргә, җыенны уздыру урыны Югары Тегермәнлек авыл мәдәният йорты.

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

7. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек , Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 80 яше тулган кешеләрдән гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Югары Тегермәнлек авылының Фрунзе,Титов урамы юллары ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;

- Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авылларының су үткәргечләрен төзекләндерүгә, авыллларга берәр су күтәртү насосы алуга һәм су скважиналарын, башняларын авыл җирлеге карамагына рәсмиләштерүгә;

- Түбән Тегермәнлек авылы җирлегендә булган юлларны тәртиптә тотуга;

- урамнарны яктырту өчен яңа яктыркычлар алуга, янган яктырткычларны алыштыруга һәм аларны төзек тотуга;

-Түбән Тегермәнлек авыл клубының арткы ягына рәшәткә тотуга.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгының 2021 елның 29 нчы октябрендә кабул иткән 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында гражданнарның узара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турындагы” карары үз көчен югалткан дип санарга.

9. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72А йорты, Түбән Тегермәнлек авылы, Мәктәп урамы, 7б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-

адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

10. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы А.Ш.Альмиев